| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАПОВО-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь 2019 ел Потапово-Томбарлы авылы № 5

**Потапово-Томбарлы, Васькино-Тойралы авыл җирлегенең Потапово-Томбарлы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

06.10.2003 елнын, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының «Потапово-Томбарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Баулы муниципаль районының Потапово-Томбарлы авыл җирлеге башлыгы

**Карары:**

1. Потапово-Томбарлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2019 елның 30 ноябренә 10:00 сәгатькә билгеләргә Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Потапово-Томбарлы авылы, Совет урамы, 35Б йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты.
2. Васькино-Тойралы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2019 елның 01 декабренә 10:00 сәгатькә билгеләргә Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Васькино-Тойралы авылы, Школьная урамы, 6А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Потапово-Томбарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, Галкино, Дубовка, Воткин бистәләрендә яшәүче аз санлы торак пунктларда яшәүчеләрдән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? - Потапово-Томбарлы авылында Совет урамының асфальт катламын чокырлар ямау-86 000 сум һәм Потапово-Томбарлы авылында юлларны кардан чистарту-10 000

сум; – Васькино Туйралы авылы зиратын койма белән әйләндереп алу-60 600 сум;

ӘЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Потапово-Томбарлы авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Потапово-Томбарлы
авыл җирлеге башлыгы
Баулы муниципаль районы
Татарстан Республикасы С.А. Козлова